Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Каратун авыл җирлеге башкарма комитетының "Каратун авыл җирлеге территориясендә хуҗасыз хайваннарны кайтару тыела торган урыннарны һәм хуҗасыз хайваннарны элеккеге хуҗасыз яшәү урыннарына кайтару турында карарлар кабул итәргә вәкаләтле затларны билгеләү турында" 2025 елның 3 мартындагы 08 номерлы карары

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, "Хайваннар белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 6.1 өлеше нигезендә Каратун авыл җирлеге башкарма комитеты карар итте:

1. Каратун авыл җирлеге хуҗасыз хайваннарны кайтару тыела торган урыннарны билгеләргә:

1) балалар өчен уен һәм спорт мәйданчыклары, спортның актив төрләре белән шөгыльләнү өчен спорт мәйданчыклары, ачык һавада спорт уеннары өчен билгеләнгән мәйданчыклар;

2) гомуми файдаланудагы территорияләр (мәйданнары, парклары, скверлары, массакүләм ял итү урыннары);

3) мәгариф оешмалары һәм сәламәтлек саклау оешмалары янындагы территорияләр;

4) мәдәният һәм сәнгать объектларына якын территорияләр;

5) җәмәгать туклануы оешмалары, сәүдә объектлары, шул исәптән стационар булмаган сәүдә объектлары янындагы территорияләр;

6) хайваннарны йөртү урыннары;

7) күпфатирлы торак йортларга якын территорияләр, аларда урнашкан, мондый йортларга хезмәт күрсәтү һәм алардан файдалану өчен билгеләнгән объектлар һәм бу территорияләрне төзекләндерү элементлары, шул исәптән парковкалар (парковка урыннары), тротуарлар;

8) зиратлар һәм мемориаль зоналар;

9) дини объектлар.

2. Хуҗасыз терлекләрне элеккеге хуҗасыз терлекләр яши торган урыннарына кайтару турында карар кабул итәргә вәкаләтле зат итеп Каратун авыл җирлеге башлыгын билгеләргә.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Каратун
авыл җирлеге башлыгы Р.С.Исмәгыйлев

Исполнительный комитет Каратунского сельского Поселения
ИНН 1608006417
ОГРН 1061672017615
Каратун авыл Җирлеге башкарма комитеты